Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 ел, 26 июнь №182

# Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупция хокук бозулары өчен җаваплылыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге N258-ФЗ номерлы "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1."Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупция хокук бозулары өчен җаваплылык турында" 2012 елның 12 декабрендәге 113 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупция хокук бозулары өчен җаваплыллыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

2.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе яки “Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге N 273-ФЗ Федераль законның 13.4 статьясына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре нигезендә;”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3.Бу карарның үтәлешен контрольләүне башлык урынбасары Л.Т.Хантимировка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Рәисе-

А.Г. Җиһаншин